ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕНАЛИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ НАЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07.04.2025** с.Верхний Налим **№ 9**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 25.12.2018 елгы 122 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күрү сәләте буенча инвалидны озата йөрүче юл күрсәтүче эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:
- файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;
- халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борындыкларда һәм тезгеннәрдә аларның хуҗалары күзәтүе астында;
- Югары Налим авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Югары Налим авылының көньяк - көнчыгыш өлешендә Тукай урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Югары Налим авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Дуслык урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Налим авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Гагарин урамыннан 60 метр ераклыкта;
Әлеге пунктның тәэсире йөртүче этләргә кагылмый.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Л.И.Сибгатуллин